ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                        КАРАР

1516                    с. Верхний Услон                    «27» 12.2018 ел

Индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырыла торган параметрларының билгеләнгән параметрларына һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге турында йә индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларын планлаштырылган төзү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының билгеләнгән параметрларына һәм (яисә) индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруга юл куймавы хакында хәбәр итү юнәлешендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында.

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны, 2018 елның 03 августындагы 340-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 02.11.2010 № 880 карары нигезендә, “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында”, Татарстан Республикасы башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставы һәм төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырыла торган параметрларының билгеләнгән параметрларына һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге турында йә индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларын планлаштырылган төзү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының билгеләнгән

параметрларына һәм (яисә) индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруга юл куймавы хакында хәбәр итү юнәлешендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгына әлеге карар белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын үтәүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.С. Хакимзянов

Минһаҗев З.З.

2 нөсхәдә